**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 елның 14 сентябре № 1689

Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитетының «2023 елга Кама Тамагы муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны тукландыруны оештыру турында» 2022 елның 27 декабрендәге 1436 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 79 статьясындагы 7.2 өлеше нигезендә, «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 6.1 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының «Кама Тамагы муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны 2023 елга тукландыруны оештыру турында» 2022 елның 27 декабрендәге 1436 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. Карарның 1 пунктын түбәндәге эчтәлекле 1.5 пунктчасы өстәргә:

«1.5. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучыларны бушлай ике тапкыр туклану белән тәэмин итү, аларны укыту муниципаль мәгариф оешмалары тарафыннан өйдә оештырылган, шул исәптән бушлай ике тапкыр туклануны акчалата компенсация белән алыштыру мөмкинлеге

2. Әлеге карар имза салынган вакыттан үз көченә керә һәм 01.09.2022 елда барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. «Кама Тамагы муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында 2023 елга укучыларның туклануын оештыру турында» 2023 елның 27 декабрендәге 1436 номерлы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 24 июлендәге 1222 номерлы карарын үз көчен югалткан дип санарга.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Е.В. Сороковнинага йөкләргә.

Җитәкче Р.М.Заһидуллин